# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Менделеевск районы буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Менделеевск районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 20-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Менделеевск районы буенча
Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд
участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Менделеевск районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полоса кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, уң якта урнашкан территорияне кертеп, тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап көньяк-көнбатышка таба Совет һәм Профсоюз урамнары кисешкән җир янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, Профсоюз урамындагы 2 нче йортны кертеп, Совет урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба Ушковлар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ушковлар урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнбатышка таба Ушковлар урамындагы 13 нче йортка кадәр уза, алга таба көньякка таба борыла һәм Ушковлар урамындагы 8 нче һәм 13 нче йортлар арасыннан, аннары Юбилей урамындагы 1 нче һәм Профсоюз урамындагы 5 нче йортлар арасыннан, 13 нче һәм 1 нче йортларны кертеп, Профсоюз һәм Юбилей урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Юбилей урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба Бурмистров урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бурмистров урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Пушкин һәм Октябрь урамнары кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Чаловский урамындагы 1 нче йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, уң якта урнашкан территорияне кертеп, грунтлы юл буйлап шәһәрнең көньяк-көнбатыш чигенә кадәр уза, алга таба "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатыш юнәлештә "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полоса кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Менделеевск муниципаль районының Абалач, Бөрешле, Енабердино, Камай, Монашево, Монай, Иске Гришкино һәм Татар Чаллысы авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полоса кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, сул якта урнашкан территорияне кертеп, тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап көньяк-көнбатышка таба Совет һәм Профсоюз урамнары кисешкән җир янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, Профсоюз урамындагы 3 нче йортны кертеп, Совет урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Ушковлар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ушковлар урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнбатышка таба Ушковлар урамындагы 13 нче йортка кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм Ушковлар урамындагы 8 һәм 13 нче йортлар арасыннан уза, аннары Юбилей урамындагы 1 нче һәм Профсоюз урамындагы 5 нче йортлар арасыннан, 8 нче һәм 5 нче йортларны кертеп, Профсоюз һәм Юбилей урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Юбилей урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба Бурмистров урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Бурмистров урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Пушкин һәм Октябрь урамнары белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Чаловский урамындагы 1 нче йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба борыла һәм, сул якта урнашкан территорияне кертеп, грунтлы юл буйлап шәһәрнең көньяк-көнбатыш чигенә кадәр уза, алга таба "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнчыгыш юнәлештә "Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полоса кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә, Ижевка, Песәй, Тихоново, Тойгуҗа һәм Турай авыл җирлекләре.

—